**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ ПР-65 18.03.2025 КАРАР № _____

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 16 декабрендәге ПР-249 номерлы «Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 2022 елның 06 апрелендәге 608 номерлы «Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында», «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карарлары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 16 декабрендәге ПР-249 номерлы карары белән расланган административ регламентларга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентларның 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү органы (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон формадагы һәр полясын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.» Бердәм портал тарафыннан тутырылган электрон формадагы поля корректлы булмаса, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән гарызнамәнең электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.»;

1.2. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 2.6.1 пунктындагы 35 пунктчасында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды»сүзләренә алмаштырырга.;

1.3. Бинаны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентының 1.5.1 пунктындагы 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йорт - Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет җитәкче И.Ш.Бариев